ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__ ________2018 ел _____

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының сайлап куелган вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 11 сентябрендәге 25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 17 июнендәге 722 номерлы карары нигезендә җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында, Актаныш авыл җирлеге Уставының 82 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затларына һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районының 2017 елның 11 сентябрендәге 25 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 бүлекнең 5 абзацында «77 статьясындагы беренче өлешенең 8 пунктында» сүзләрен «муниципаль хезмәткәр күрсәтелгән нигезләрдә эштән китсә» сүзләреннән соң өстәргә.

1.2. 6 бүлекнең 3 пунктында «ундүрт вазыйфаи окладтан артмаган» сүзен «тугыз ярым вазыйфаи окладтан артмаган» сүзләренә алмаштырырга.

1 3. 4 бүлекнең 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр башлыкларының һәм аларның урынбасарларының хезмәте өчен түләүнең шартларын җайга сала торган муниципаль хокукый акт билгеләнгәндә, тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләүләр күрсәтелгән өстәмәләрнең күләме әлеге бүлекнең 1 пунктында билгеләнгән күләмнән артып китә алмый. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү чыгымнары күләме тиешле вазыйфа буенча елына өч айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә торган нормативтан арта алмый.»

1 бүлекнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «муниципаль хокукый актларда, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләрне үтәп, шулай ук түбәндәге өстәмә түләүләр дә каралырга мөмкин:

1) норматив булмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә ай саен түләнә торган компенсация түләү;

2) төп хезмәт бурычларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм

редакцияләү һәм аларны югары юридик белемле юрист яки башкаручы сыйфатында визалау (юридик эш өчен өстәмә)кергән муниципаль хезмәткәрләргә ай саен түләү;

3) муниципаль хезмәткәрләргә фәннәр кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе, фәннәр докторының гыйльми дәрәҗәсе өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләүләр;

4) муниципаль хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү.»

1.6. 1 бүлекнең 4 абзацына түбәндәге эчтәлекле 8 нче пунктча өстәргә:

- «8) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү.».

1.7. 1 бүлекнең 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләмнәре

»

| Вазифаның атамасы | Айлык вазыйфаи окладның күләме (сум) | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| Башкарма комитет җитәкчесе | | |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 2400 | 2110 |
| | | |

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендында, Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш авыл җирлеге
Советы Рәисе урынбасары И.Ш.Бариев